КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 июнь г.Казань № 674

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Дипломы һәм Мактау билгесе тасвирламасын раслау турында» 1994 ел, 20 июнь, 284 нче карарына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Дипломы һәм Мактау билгесе тасвирламасын раслау турында» 1994 ел, 20 июнь, 284 нче карарына 2 нче кушымтага (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 ел, 22 ноябрь, 776 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1994 ел, 20 июнь, 284 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 1 июнь, 674 нче
карары редакциясендә )

Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты
Дипломы тасвирламасы

<table>
<tr>
<td>Татарстан Республикасы<br>Дәүләт гербы рәсеме<br><br>Фән һәм техника өлкәсендә<br>Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе<br>лауреаты<br><br>ДИПЛОМЫ<br><br>№ _____<br><br>ИВАНОВ<br>Иван Ивановичка<br>(атасының исеме - булганда)<br><br>«Премия бирелә торган эшнең исеме»<br>хезмәте өчен<br><br>БИРЕЛДЕ<br><br>Татарстан Республикасы<br>Рәисе Р.Н. МИҢНЕХАНОВ<br><br>Казан<br>20__ ел</td>
<td>Изображение Государственного герба<br>Республики Татарстан<br><br>ДИПЛОМ<br><br>№ _____<br><br>лауреата Государственной премии<br>Республики Татарстан<br>в области науки и техники<br><br>ВЫДАН<br><br>ИВАНОВУ<br>Ивану Ивановичу<br>(отчество – при наличии)<br><br>за работу «Название работы,<br>за которую присуждена премия»<br><br>Раис<br>Республики Татарстан Р.Н. МИННИХАНОВ<br><br>Казань<br>20__ год</td>
</tr>
</table>

Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты дипломының ике бите була (һәркайсы 170 х 230 миллиметр зурлыгында) тулы төсле мөһер белән, фоны - ачык зәңгәр градиент, рус һәм татар телләрендә.

Битнең өстендә алтынны хәтерләткән төс белән Татарстан Республикасы Дәүләт гербының 40 миллиметр зурлыгындагы сурәте басылган. Битнең сул һәм уң кырыеннан симметрияле рәвештә бүленгән.

______________________